ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр
авылы,Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» май 2025 ел** **№ 14**

**Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә пиротехника эшләнмәләреннән файдалану турында**

РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 28 августындагы "Россия Федерациясе һава хәрәкәтен оештыруның Бердәм системасы турында" 901 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы "Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында" 138 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган РФдә янгынга каршы режим кагыйдәләре нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Пиротехник әйберләрдән файдалану өчен рөхсәт ителгән урын итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:
   - Яңа Кенәр авылы, авылның көньяк читендә, Сабантуй мәйданы;
   - Сөрде авылы, Совет урамы, 4 йорттан 100 м.
   - Түбән Оры авылы, Киров урамы, 1 йорттан 100 м.
   - Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17 А йорттан 70 м.

Биеклеге 50 метрдан артыграк булган салютлар һәм фейерверклар үткәргәндә, шулай ук җир яисә су өслегенә һава юллары полосаларын проекцияләү чикләрендә салютлар һәм фейерверклар биеклегенә бәйсез рәвештә һава пространствосыннан файдалану Россия Федерациясе Һава хәрәкәтен оештыруның бердәм системасы оператив органы (алга таба - Вәкаләтле орган)рөхсәте белән гамәлгә ашырыла.

Фейерверк уздыру өчен вәкаләтле органнан рөхсәт алырга кирәк. Язма рөхсәттән башка муниципаль берәмлек территориясендә фейерверк уздыру тыела.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетының 2024 елның 5 декабрендәге «2024-2025 еллардагы Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларына әзерлек турында» 27 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм Яңа Кенәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: Яңа Кенәр авылы, Совет урамы, 10

йорт; Сөрде авылы, Совет урамы, 48 йорт; Шурабаш авылы, Гагарин урамы, 17 А йорт.

4. Әлеге карарны куллануны контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә. Гайфуллин